РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ
РУНГИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЫРЫНГЫ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ　　　　КАРАР

13.03.2025　　　　1-103

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Ырынгы авыл җирлеге Советының 2013 елның 22 февралендәге 1-35 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Ырынгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карарын гамәлдән чыгару хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга, «Шәһәр төзелеше эшчәнлегендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы һәм һәм Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Ырынгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2025 елның 27 февралендәге 195/о номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Ырынгы авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Ырынгы авыл җирлеге Советының 2013 елның 20 февралендәге 1-28 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Ырынгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http:pravo.tatarstan.ru адресы буенча басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы

Муниципаль берәмлекләре порталында https://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча халыкка игълан ителергә тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Ырынгы авыл җирлеге башлыгы Р.И.Гордеев